**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Кураз авылында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

21.11. 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Кураз авылы гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Песәй авылы җирлегенең Кураз авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, карамагында балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия армиясенә хәрби хезмәткә чакырылганнардан 500 сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итәргә һәм кертергә;

2. Алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. вак таш сатып алу (китерү, тигезләү);
2. кышкы чорда юлларны кардан чистарту;
3. балалар мәйданчыгын саклау өчен материал сатып алу;
4. балалар мәйданчыгының коймасын урнаштыру;
5. су скважинасы өчен насос сатып алу.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Песәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы В.И.Мөхаматгалеев